РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башкарма комитеты

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«24» октябрь 2022 ел** **№ 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2022 елның 12 ноябренә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2022 елның 12 ноябре 09.00 сәг тән 10.00 сәг кә кадәр;
- үткәрү урыны – Ирекле авылы, Подгорная ур., Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга куелган һәйкәл яны торриториясе дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 31 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адрес буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Ирекле авылы, Подгорная урамы үзәге адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Ирекле торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Ирекле торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Илбәк авыл җирлеге  Ирекле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 350 сумга киметеп,  үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ирекле авылында чишмәне койма белән әйләндереп алу, төзекләндерү (төзелеш материаллары, хуҗалык товарлары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru  һәм Ирекле авылы, Подгорная урамы үзәге;  Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина